ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧУВАШСКО-ЕЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
422962, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
с. Чувашский Елтан, ул.Школьная, д.15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУВАШ ЯЛТАНЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422962, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Чуваш Ялтан авылы,
Мәктәп ур., 15 йорт

тел. 884342 3-69-33, e-mail: Celt.Ctp@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.12.2019 ел № 12

Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Чистай муниципаль районының «Чуаш Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында (Акбулат авылы гражданнар җыенының 2019 елның «18» ноябрендәге 1 номерлы карары, Чуаш Ялтаны авылы гражданнар җыенының 2019 елның «22» ноябрендәге 2 номерлы карары, Ишәле авылы гражданнар җыенының 2019 елның 23 ноябрендәге 3 номерлы карары) Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю буенча тәкъдим ителгән Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http:/chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Чуаш Ялтаны авыл
җирлеге башлыгы С.М.Егоров

Чистай муниципаль районы

Чуаш Ялтаны авыл җирлегенең
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 24 декабре 12 номерлы
карары белән расланды

Чистай муниципаль районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 10 мартына кадәр Чистай муниципаль районының Чуаш Ялтаны авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, сугышта һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) бланкы, Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерү юлы белән яисә имза куеп тапшыру, яки почта элемтәсе аша җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Чистай муниципаль районының «Чуаш Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмаларын) Чистай муниципаль районы Чуаш Ялтаны авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Чистай муниципаль
районының
Чуаш Ялтаны авыл җирлеге
гражданнарының үзара салым
акчаларын җыю Тәртибенә
кушымта

ТР Чистай муниципаль районы ___________________________ авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № ________________

Түләүченең Ф. И. атасының исеме
_______________________________________________________________________________
Адрес: _________________________________________________________________
_____________________________________________________________________ нигезендә
Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: _________________ срогына кадәр, ___________ суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк.
түбәндәге реквизитлар буенча:_____________________________________________________
Алучы Банк БИК ________________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучы Сч. № ________________________________________
ИНН ____________________________________________
КПП ____________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ____________________
Түләү билгеләү
_______________________________________________________________________________
Җитәкче __________________ __________________________________________
М.П. (имза) (тулы имза)
- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -
хәбәр (хәбәрнамә) № _____
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф. И. атасының исеме ____________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________________________
Алды «__» ________________ 20__ ел. ________________________________________
(түләүче имзасы)

Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше ______________________ авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.